**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге генераль планы проекты буенча халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итү**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге генераль планы проекты буенча **халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итәбез.**

**2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

- территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә:
- җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы;
- торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре)картасы;
- функциональ зоналар картасы;
- торак пунктлар чикләре турында белешмәләр;
- генераль планны текст рәвешендә нигезләү материаллары (әйләнә-тирә мохитне саклау):
- территориядән заманча файдалану картасы;
- инженерлык инфраструктурасы картасы;
- табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр, гражданнар оборонасы чаралары картасы;
- территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (гамәлдәге нигезләмә);
- территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (проект тәкъдиме)

**3. Проект буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм сроклары:**

Проект буенча халык тыңлаулары 2026 елның 29 маеннан 2026 елның 15 июненә кадәр чорда үткәрелә.

Халык тыңлауларын үткәрү процедурасы түбәндәге этапларны үз эченә ала:

- халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- халык тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- халык тыңлаулары беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Халык тыңлауларында катнашучылар даирәсе:**

Проект буенча халык тыңлауларында катнашучылар булып тора:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре,
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

**5. Чикләрендә халык тыңлаулары уздырыла торган территория:** Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге.

**6. Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы: 05.06.2026**

- Шөкрәле авылы, Большая ур., 12, авыл клубы бинасы янында;
- Калиновка авылы, К.Маркс ур., һәлак булган авылдашларга истәлек тактасы янында.
- Күперле авылы, Большая ур., 35, балалар мәйданчыгы территориясендә;
- Суровка авылы, Поперечная ур., балалар мәйданчыгы янында;
- Яңа Троицкий авылы, Ленин ур., 11, авыл мәдәният йорты;

**7. Проект экспозициясен үткәрү сроклары:** 2026 елның 5 июненнән 2026 елның 15 июненә кадәр чорда.

**8. Экспозицияне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**дүшәмбе-җомга 09:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр.

**9. Халык тыңлауларында катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм формасы:**

2026 елның 5 июненнән 2026 елның 15 июненә кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы 12 өлеше нигезендә идентификация узган халык тыңлауларында катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- рәсми сайт аша;
- халык тыңлауларын оештыручы адресына язма рәвештә яки электрон документ формасында: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 101 каб. (дүшәмбе - җомга, 09:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр);
- түбәндәге адрес буенча халык тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язу юлы белән:

**- Яңа Троицкий авылы, Ленин ур., 11, авыл мәдәният йорты (дүшәмбе-җомга 09:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр);**

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы 12 өлеше нигезендә идентификация узган халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яки телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

**10. Халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча халык тыңлаулары **2026 елның 15 июнендә узачак:**

14:20 Шөкрәле авылы, Большая ур., 12, авыл клубы бинасы янында;

14:45 Калиновка авылы, К.Маркс ур., һәлак булган авылдашларга истәлек тактасы янында.

15:05 Күперле авылы, Большая ур., 35, балалар мәйданчыгы территориясендә;

15:30 Суровка авылы, Поперечная ур., балалар мәйданчыгы янында;

16:00 Яңа Троицкий авылы, Ленин ур., 11, авыл мәдәният йорты;

**11. Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**

Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект 2026 елның 5 июненнән Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) «Документлар/иҗтимагый һәм халык тыңлаулары» өстәмә битендә урнаштырылачак.

**12. Әлеге хәбәрнамәне** «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 15AE296FD75F49CE6CBF538F55CA0DD1
Владелец: Маняпов Линар Нурисламович
Действителен с 11.11.2025 до 04.02.2027

Л.Н. Маняпов